**СОВЕТ СУКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422729, Высокогорский район РТ,
с. Суксу, ул.Школьная, 9а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СУЫКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422729, ТР Биектау районы,
Суыксу авылы, Мәктәп ур., 9а

Тел./факс: +7(84365) 61-8-43,e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
27 май 2015 ел

**РЕШЕНИЕ**
№ 217

## Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге "Физик затлар милкенә салым турында» 2014 елның 10 ноябре, № 182 Совет карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 ноябрендәге «Физик затлар милкенә салым турында»гы 182 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктта:

а) 1 пунктчада:

түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларында, шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 10 пунктындагы икенче абзацында каралган салым салу объектында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннар « Ставкасы бер гаражга яки машина-урынга карата салым түләүченең теләге белән билгеләнә.»;

б) 4 пунктчада:

икенче һәм өченче абзацларын үз көчләрен югалткан дип таныргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«2015 елда-6) 1,5 процент, 2016 елда - 1,8 процент, 2017 елда - 2 процент һәм алдагы елларга карата-2 процент:

Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата.»;

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Ике фатирдан торган күп фатирлы торак йортта фатирга милек хокукы булган физик затларга әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метрының кадастр бәясендәге салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә ташламалар билгеләргә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламаларның суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукында пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектә катнашучыларның һәркайсы өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Бу очракта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы аны исәпкә алмыйча исәпләнгән салым суммасыннан артып китә алмый.».

1.3. 3 һәм 4 пунктларны 4 һәм 5 пунктлары дип санарга.

2. Әлеге карар 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми интернет-порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш http://pravo.tatarstan.ru/ - Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Суыксу авыл җирлеге башлыгы Р.С.Низамиев